# Әнием – иң газиз кешем

Изге ана – мөкәтдәс җан,
Күпме җырлар сиңа языла.
Җан сазымнан, саф йөрәктән
Дан җырлыймын синең назыңа.
Җырым очсын еракларга,
Карлыгачтай кебек кагынып.
Бәхет бирсен, шатлык бирсен
Йөрәк кылларына кагылып.

КУШЫМТА
Әнием, әнкәем, иң газиз кешем,
Дөнья яктысын син биргәнсең.
Гомрем юлында фәрештә булып
Бер ходайдан, ахры, килгәнсең.

2. Дөнья ямен, яшәү тәмен
Тик син, әнкәм, миңа бирәсең.
Борчуларым, кайгыларым,
Җаның белән тоя беләсең.
Илһам бирсен мәхәббәтең
Кояш кебек җылыта җаның.
Синдәй өз(е)леп яратучым
Дөньяларда булырмы тагын?